*Туфан Миңнуллин*

# Җылы күңелле иде…

Мәгъсум дә китеп барды… Калын кашлары астыннан, күзлек кысалары өстеннән кешеләргә сынап һәм сокланып төбәлгән карашы гына калды. Әйе, ул бервакытта да әйтәсе сүзен карашын яшереп әйтмәде. Фикерен йә сүзен күзгә туры карап, ләкин кеше хәтерен калдырмаслык итеп җиткерә иде. Шуңа күрә аны язучыларның олы яшьтәгеләре дә, әле борын төртеп килгәннәре дә яратты, үзенә тиң итеп күрде.

Үземнән өлкән булса да, мин аңа, яратып һәм якын итеп, «Макс» дип эндәшә идем. Миннән күпкә яшь шагыйрьләр дә аның белән «Хуҗин» дип, үз итеп сөйләшә иде. Бөтенебез яратса да, бөтенесенә дә ярый белүче шома-хәйләкәр түгел иде ул. Аңарда Сабаягы кешеләренең холкы ярылып ята иде. Үзе ышанган, үзе дөрес дип тапкан фикереннән аны беркайчан да чигендереп булмады. Юк, бу гади кирелек түгел, ә үз принципларыңа турылыклы булып калу. Ә аның принцибы мондый иде – һәр кеше горур булырга, кеше кешегә мескенләнеп баш имәскә һәм бүтәннәрне дә үзенә баш иярүгә мәҗбүр итмәскә тиеш.

Соңгы елларда Мәгъсум белән еш аралаша алмадык. Ләкин аның барлыгын, исәнлеген тоеп яшәдем. Очрашканда, бер-беребезгә сынашып карап тора идек. Мөнәсәбәтләрнең элеккечә дустанә булуын күреп, калын каш астындагы сизгер, акыллы күзләре елмая иде. Җылы күңелле кеше иде шул!

*2008*



*Хикәяләр остасы Мәгъсум Хуҗин*



*Күренекле драматург Туфан Миңнуллин*

*Разил Вәлиев*

# Ничә ел янәшә

Мәгъсум ага белән без озак еллар буе бер-берсенә терәлешеп торган йортларда күршеләр булып яшәдек. Эштә дә күршеләр булдык, мин эшләгән «Ялкын» журналы белән аның «Чаян»ы нәшриятның тугызынчы катында янәшә урнашкан иде. Көн саен диярлек иртән эшкә бергә барабыз, кич бергә кайтабыз, өстәвенә көне буе да гел бергә. Әмма, ни гаҗәп, аның белән күпме сөйләшеп тә сүз бетми, ул сине ялыктырмый, туйдырмый, киресенчә, өйгә кайтып җиткәч тә, без, әңгәмәне өзә алмыйча, үзебезнең йортларны кат-кат урап йөри идек.

Ул риясызлыгы, хөсетсезлеге, «сакаллы сабыйлыгы» белән кешеләрне үзенә тартып тора, аның белән аралашканнан, фикер алышканнан соң, күңелең мунча кереп, чистарынып калгандай була.

Карап торырга шактый басынкы, хәтта телсез-тешсез, юашрак кеше күренсә дә, хаксызлык белән очрашканда яисә кемнедер нахакка гаепләсәләр, ул кинәт кенә кабынып, ярсып китә иде. Ә инде берәрсенең игелекле гамәлен күрсә яисә күңеленә хуш килгән берәр әсәр укыса,

*Татарстан Язучылар берлегенең Әдәби фонды идарәсе утырышыннан соң. Беренче рәттә (сулдан уңга): Лирон Хәмидуллин, Әхсән Баян, Мәгъсум Хуҗин, Туфан Миңнуллин, Салисә Гәрәева; икенче рәттә: Галимҗан Гыйльманов, Зиннур Мансуров, Разил Вәлиев, Ләбиб Лерон, Гәрәй Рәхим, Шаһинур Мостафин, Рәдиф Сәгъди, Данил Салихов*





*Проза секциясе утырышыннан соң. Беренче рәттә (сулдан уңга): (...), Мөсәгыйт Хәбибуллин, Атилла Расих, Гариф Ахунов, Наил Сабиров, Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким, (...), Фатих Хөсни; икенче рәттә: Ләбибә Ихсанова, Вакыйф Нуруллин, Нәби Дәүли, Мөхәммәт Мәһдиев, Солтан Шәмси, Мөдәррис Вәлиев, Мәгъсум Хуҗин, (...), Зиннур Хөснияр, Рашат Низами, Нәркис Җәлилов, Мәгъсум Насыйбуллин, Фәрваз Миңнуллин. 80 нче еллар*

соклануын яшерә алмыйча, бүлмәдән бүлмәгә кереп, шул хакта сөйләп йөри.

Безнең тугызынчы катта өч журнал редакциясенең өч мәшһүр мөхәррире, азау теше чыгарган илле-алтмыш журналист-язучы булса да, штаб бүлмәбез — «көфер почмагыбыз» һәрчак Мәгъсум ага янында булды. Киңәш кирәк булса — киңәш-табыш итеп, акылга мохтаҗлык артса — акыл эстәп, акчабыз бетсә — әҗәт сорап, һәммәбез аның катына юнәләбез. Ул башта сүзен яратып кына орышудан башлый, үзе сине битәрләгәндәй итә, ә күзләре елмая, йөзе балкып, күңелеңне яктыртып тора. Ничә ел янәшә эшләп һәм яшәп тә, мин аның кемдер турында нахак сүз әйткәнен, кемдер артыннан гайбәт сөйләп калганын, кемнедер рәнҗеткәнен күрмәдем. Әйтерсең лә ул Ходай Тәгалә тарафыннан бары тик изгелекләр эшләү өчен генә җиргә иңдерелгән канатсыз фәрештә иде.

Бу кечкенә язмада мин аның кайбер тышкы сыйфатларын гына искә алдым. Ә аның күңел дөньясы гаҗәеп бай, нәзберек һәм нәзакәтле, аны аңлар өчен, Мәгъсум ага Хуҗинның иҗат дөньясына озаклап сәяхәт кылырга кирәк.

*2008*

*Марсель Галиев*

# Көмешче-оста

Сүз кадерен тоеп яза белгән тирән фикерле хикәяләр остасы, әдәбият турында тәмле итеп ихластан сөйли, кайгырта торган остаз иде ул. Хәтеребездә шулай булып калыр да…

Үзе дә шул төбәктән чыккан шәхес буларак, ул Казан артының борынгыдан килгән һөнәрчеләре турында горурланып сөйли иде. Әгәр әдәбият юлын сайламаса, ул, һичшиксез, көмешче-оста булыр иде; сандугач керфеге нәзбереклегендәге көмеш «җепләрдән» үреп, хикмәтле беләзекләр, талир тәңкәләр, йөзек-алкалар ясап, кешеләргә нурлы куаныч китерер иде. Әдәбиятта ул, сүзгә көмеш тылсымнары өретеп, көмеш хикәяләр язды.

Тыштан кырыс күренүе болай гына, хисси күңелен түгелдермәс өчен генә иде.

Битәрләгән кебек сөйләшүе аерым бер якын мөнәсәбәтен белдерүе иде.

Әдәбиятка бөтенләе белән ихластан бирелгән вөҗданлы зат буларак, чүл комнары каплап килгән рухи дөньябызда ул үзенчә бер оазис иде. Аның хикәяләр чишмәсенә килеп, зәмзәм суына ничә тапкырлар иелербез әле…

Августның матур бер көнендә «Идел-Пресс» янындагы каеннар арасыннан сузылган сукмактан киләм, «бөек» дип дәшкән тавышка ялт борылып карыйм. Мәгъсум ага таягына таянып, рәхәтләнеп көлеп тора:

— «Бөек» дигәнгә борылып карадың бит, чукынчык! — ди.

Мин каядыр ашыга идем, аның сөйләшәсе, нидер әйтәсе килә.

— Кайсы редакциядә буласың, Мәгъсум ага? Мин бераздан әйләнеп киләм, — дим.

— Ул чакта мин киткән булырмын шул инде, — ди.

Ашыгылган… («Хәзергә» дип хушлашуың мәңгегә булырга мөмкин икәне онытыла шул.) Әлеге сукмактан узган саен, каеннар арасыннан ул дәшәр кебек. Борылып каракарама, киткән шул инде, китеп барган…

Сукмакка көз хәбәре — сары яфраклар гына пышылдап коела…

*«Мәдәни җомга», 2010, 12 сентябрь*

*Марсель Галиев һәм Мәгъсум Хуҗин*



*Сания Хафизова,*
*Нурания Рәхимова*

# Безнең олы абыебыз

Мәгъсум абый безнең иң олы абыебыз иде. Ул яшь вакытыннан табигатьне бик яратты. Очрашканда, гел Саба авылы турында, Тенеки, Тимершык авыллары кешеләре, туганнар хакында яратып сөйли иде. Бервакытны авылга кайтканда, Теләчене узгач, Мишә елгасына балык тотарга кайтып йөргәнен, якын-тирәдәге авылларга җәяүләп барганнарын җайлап кына сөйләгәне истә калган. Студент вакытында каникулга кайткач, энебез Илгиз белән җырлыйлар иде. Абый: «Әйдә, «Баламишкин» җырын җырлыйк әле», — дисә, Илгиз, шаяртып, башка җыр башлый. Аннары бергә көлешәләр иде.

Казанда укыган вакытында, сыйныфташы Рафаэль абый белән кайтып, Сабантуйларда көрәшәләр иде. Гомумән, сагынып искә алырлык вакыйгалар күп инде. Без Мәгъсум абыйны бик юксынабыз, сагынабыз.

*2010, февраль*



*Әтисе Хәмидулла һәм әнисе Бибирауза*



*Биш туган. Сулдан уңга (утырганнар): сеңлесе Нурания, Мәгъсум Хуҗин, сеңлесе Сания; басканнар: энеләре Васил һәм Илгиз*